РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«19» февраль 2025г. г. Альметьевск № 341

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең һәм Башкарма комитетының 2024 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм 2025 елга бурычлары турында хисап

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тәкъдим иткән хисапны карап,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең һәм Башкарма комитетының 2024 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм 2025 елга бурычлары турындагы хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына 2025 елга беренче чираттагы бурычларны билгеләргә:

- милли проектларны, федераль, республика һәм муниципаль программаларны, Әлмәт муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру;
- Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгышын икътисадый үстерү максатларында Әлмәт икътисадый зонасы эчендә муниципальара хезмәттәшлек чараларын гамәлгә ашыру;
- махсус хәрби операция зонасында хәрби хезмәт узучы мобилизацияләнгәннәргә, хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм чараларын тәэмин итү;
- сәнәгать парклары инфраструктурасын үстерү;
- район икътисадында кадрлар кытлыгын киметүгә юнәлдерелгән эш башкару;
- күп балалы гаиләләр өчен индивидуаль торак төзелеше өчен бүлеп бирелгән җир кишәрлекләре булган микрорайоннарда юл инфраструктурасын үстерү;
- торак төзелешен үстерү максатларында шәһәр территорияләрен экстенсив үстерү өчен ресурслар белән тәэмин итүче инфраструктура булдыру чараларын гамәлгә ашыру;
- шәһәр коммуналь инфраструктурасы челтәрләрен модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру;

- авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру;

- авыл җирлекләре территорияләрендә эшлекле активлыкны арттыру һәм эшкуарлыкны үстерү чараларын гамәлгә ашыру;

- урта һөнәри белем бирү учреждениеләренең белем бирү мәйданнарын киңәйтү чараларын гамәлгә ашыру;

- Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгышында бердәм медицина кластерын төзү эшен оештыру.

3. Районның Башкарма комитетына әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар, социаль мәсьәләләр буенча даими комиссияләренә йөкләргә

Муниципаль район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы — Р.Е. Әфләтунова